МУНИЦИПАЛЬНОЕ КАЗЕННОЕ УЧРЕЖДЕНИЕ
«ПАЛАТА ИМУЩЕСТВЕННЫХ И ЗЕМЕЛЬНЫХ ОТНОШЕНИЙ»
ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Полковая ул., 9, с. Высокая Гора,
Высокогорский район, Республика Татарстан, 422701

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
«МИЛЕК ҺӘМ ҖИР МӨНӘСӘБӘТЛӘРЕ ПАЛАТАСЫ»
МУНИЦИПАЛЬ КАЗНА УЧРЕЖДЕНИЕСЕ
Полковая урамы, 9, Биектау поселогы,
Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422701

Тел.: +7 (84365) 3-28-54, e-mail: pizobiektau@mail.ru

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

**14 октябрь, 2025 ел** **№ 1465-р**

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Милек һәм җир мөнәсәбәтләре палатасының «Җир кишәрлеге бирүне алдан килештерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2021 елның 21 сентябрендәге 1300-р боерыгына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Җир кодексының 39.15 статьясы, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Пространстволы мәгълүматларның милли системасы» Бердәм цифрлы платформасы» Федераль дәүләт географик мәгълүмат системасы турында» 2022 елның 07 июнендәге 1040 номерлы карары нигезендә

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Милек һәм җир мөнәсәбәтләре палатасының 2021 елның 21 сентябрендәге 1300-р боерыгы белән расланган Җир кишәрлеге бирүне алдан килештерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2 бүлекнең 2.4.1 пунктындагы беренче абзацын яңа редакциядә бәян итәргә:

«2.4.1. Муниципаль хезмәт күрсәтү срогы - 15 эш көне».

1.2. 2 бүлекнең 2.5.2 пунктындагы 2 пунктчасын яңа редакциядә бәян итәргә:

«5) әгәр сорала торган җир кишәрлеген төзү алда торганда һәм мондый җир кишәрлеге төзелергә тиешле территорияне ызанлау проекты булмаган очракта, территория чикләренең характерлы нокталары координаталарын күрсәтеп, җир кишәрлеген урнаштыру схемасы. Җир кишәрлеген урнаштыру схемасы xml форматында яисә Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең «Территориянең кадастр планында җир кишәрлеге яисә җир кишәрлекләрен урнаштыру схемасын әзерләүгә һәм территориянең кадастр планында җир кишәрлеген яисә җир кишәрлекләрен урнаштыру схемасын электрон документ рәвешендә әзерләгәндә, территориянең кадастр планында җир кишәрлеген яисә җир кишәрлекләренең урнаштыру схемасы форматына карата таләпләрне раслау, аны әзерләү кәгазь чыганактагы документ рәвешендә гамәлгә ашырыла торган территориянең кадастр планында җир кишәрлеген яисә җир кишәрлекләрен

урнаштыру схемасы формалары» 2022 елның 19 апрелендәге П/0148 боерыгында каралган башка форматларда электрон документ рәвешендә бирелә.

Җир кишәрлеген урнаштыру схемасын электрон документ рәвешендә әзерләү пространстволы мәгълүматларның милли системасы эшчәнлеген тәэмин итә торган Федераль дәүләт географик мәгълүмат системасыннан файдаланып гамәлгә ашырылырга мөмкин.».

1.3. 2 бүлекнең 2.5.2 пунктындагы 5 пунктчасын яңа редакциядә бәян итәргә:

«5) «Гражданнар тарафыннан үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык һәм яшелчәчелек алып бару турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2017 елның 29 июлендәге 217-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә төзелгән коммерциягә карамаган бакчачылык яисә яшелчәчелек ширкәт әгъзаларының реестры, җир кишәрлеге бирүне алдан килештерү турында яисә мондый ширкәткә җир кишәрлеген түләүсез файдалануга бирү турында гариза бирелгән очракта;».

1.4. 2 бүлекнең 2.8.3.2 пунктындагы 3 пунктчасын яңа редакциядә бәян итәргә:

«3) җир кишәрлеге бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир кишәрлеге коммерциягә карамаган бакчачылык яисә яшелчәчелек ширкәтенә бирелгән җир кишәрлеген бүлү нәтиҗәсендә төзелгән, әлеге ширкәт әгъзасының (әгәр мондый җир кишәрлеге бакча яисә яшелчә бакчасы кишәрлеге булса) яисә бакчачылык яисә коммерциягә карамаган яшелчәчелек ширкәтендә катнашу (әгъзалык) хокукына ия булмаган, федераль законнар, Россия Федерациясе субъектлары законнары нигезендә җир кишәрлеген беренче чиратта яисә чираттан тыш сатып алу йә әлеге Кодексның 39_18 статьясы нигезендә җир кишәрлеге сатып алу хокукына ия гражданның (әгәр мондый җир кишәрлеге бакча кишәрлеге булса) мондый гариза белән эш итү очракларыннан тыш, шулай ук гражданнар үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык яисә яшелчәчелек алып барган территория чикләрендә урнашкан җир кишәрлекләре милекчеләреннән тыш (әгәр җир кишәрлеге гомуми билгеләнештәге җир кишәрлеге булса);».

1.5. 2 бүлекнең 2.8.3.2 пунктындагы 6.2 пунктчасын яңа редакциядә бәян итәргә:

«6.2) Россия Федерациясе Җир кодексының 27 статьясындагы 5 пункты нигезендә дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге түбәндәге җир кишәрлекләре әйләнештә чикләнгән була:

а) әгәр әлеге Кодекста һәм махсус сакланылучы табигать территорияләре турында Россия Федерациясе законнарында башкасы каралмаган булса, Россия Федерациясе Җир кодексының 27 статьясындагы 4 пунктында күрсәтелмәгән махсус сакланылучы табигать территорияләре чикләрендә;

б) урман фонды җирләре составыннан;

в) дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге су объектлары урнашкан чикләрдә;

г) Россия Федерациясе халыкларының аеруча кыйммәтле мәдәни мирас объектлары, Бөтендөнья мирасы исемлегенә кертелгән объектлар, тарихи-мәдәни тыюлыклар, археологик мирас объектлары, музей-тыюлыклар биләгән;

д) оборонаны һәм иминлекне, оборона сәнәгатен, таможня ихтыяҗларын тәэмин итү өчен бирелгән һәм Россия Федерациясе Җир кодексының 27 статьясындагы 4 пунктында күрсәтелмәгән;

е) ябык административ-территориаль берәмлекләр чикләрендә Россия Федерациясе Җир кодексының 27 статьясындагы 4 пунктында күрсәтелмәгән;

ж) диңгез транспорты, эчке су транспорты, һава транспорты объектларын, һава хәрәкәтен һәм судно йөрешен навигация белән тәэмин итү корылмаларын, гомуми файдаланудагы тимер юл транспорты инфраструктурасы объектларын, шулай ук федераль әһәмияттәге, региональ әһәмияттәге, муниципальара әһәмияттәге яисә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, реконструкцияләү һәм (яки) эксплуатацияләү (алга таба - урнаштыру) өчен билгеләнгән;

з) космик инфраструктура объектлары урнашкан;

и) гидротехник корылмалар объектлары астындагы җирләр;

к) агулы матдәләр, наркотик чаралар җитештерү өчен бирелгән җирләр;

л) куркыныч калдыклар, радиоактив матдәләр белән пычранган, биоген пычратуга дучар ителгән, деградациягә дучар ителгән башка җирләр;

м) дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗлар өчен резервланган җирләр чикләрендә урнашкан җирләр;

н) эчә торган су белән һәм хуҗалык-көнкүреш су белән тәэмин итү чыганакларын санитар саклау зоналарының беренче поясында;

о) табигый дәвалау ресурсын санитар (тау-санитар) саклау округының беренче зонасы чикләрендә.»

1.6. 2 бүлекнең 2.8.3.2 пунктындагы 8-10 пунктчаларсын яңа редакциядә бәян итәргә:

«8) җир кишәрлеге бирү турында гаризада күрсәтелгән җир кишәрлеге территорияне комплекслы үстерү турында аңа карата шартнамә башка зат белән төзелгән йә, әгәр күрсәтелгән карарны гамәлгә ашыру өчен территорияне комплекслы үстерү турында шартнамә төзү таләп ителмәсә, аны комплекслы үстерү турында карар кабул ителгән территория чикләрендә урнашкан, җир кишәрлеген бирү турында гариза белән мондый җир кишәрлегендә урнашкан бина, корылма, андагы урыннар, тәмамланмаган төзелеш объекты милекчесе яисә мондый җир кишәрлегенең хокук иясе мөрәҗәгать иткән очраклардан тыш;

9) җир кишәрлеге бирү турында гаризада күрсәтелгән җир кишәрлеге территорияне комплекслы үстерү турында аңа карата шартнамә башка зат белән төзелгән йә, әгәр күрсәтелгән карарны гамәлгә ашыру өчен территорияне комплекслы үстерү турында шартнамә төзү таләп ителмәсә, аны комплекслы үстерү турында карар кабул ителгән территория чикләрендә урнашкан, яисә җир кишәрлеге территорияне комплекслы үстерү турында башка зат белән шартнамә төзелгән җир кишәрлегеннән төзелгән, моңа мондый җир кишәрлеге федераль әһәмияттәге объектларны, региональ әһәмияттәге объектларны яисә җирле әһәмияттәге объектларны урнаштыру өчен билгеләнгән һәм мондый җир кишәрлеген бирү турында гариза белән күрсәтелгән объектларны төзүгә вәкаләтле зат мөрәҗәгать иткән очраклар керми;

10) җир кишәрлеге бирү турында гаризада күрсәтелгән җир кишәрлеге территорияне комплекслы үстерү турында аңа карата шартнамә башка зат белән

төзелгән йә, әгәр күрсәтелгән карарны гамәлгә ашыру өчен территорияне комплекслы үстерү турында шартнамә төзү таләп ителмәсә, аны комплекслы үстерү турында карар кабул ителгән территория чикләрендә урнашкан, территорияне планлаштыру буенча расланган документлар нигезендә ул федераль әһәмияттәге объектларны, региональ әһәмияттәге объектларны яисә җирле әһәмияттәге объектларны урнаштыру өчен билгеләнгән, моңа җир кишәрлеген арендага бирү турында гариза белән территорияне комплекслы үстерү турында шартнамә төзелгән зат мөрәҗәгать иткән очраклар керми, ул әлеге затның күрсәтелгән объектларны төзү буенча йөкләмәсен күздә тота;».

1.7. 2 бүлекнең 2.8.3.2 пунктындагы 16 пунктчасында «чик» сүзен төшереп калдырырга.

1.8. 3.5.3 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:

«3.5.4. Регламентның 3.5.2 пунктында күрсәтелгән процедураларны үтәү техник мөмкинлек булганда, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен билгеләнгән автоматлаштырылган мәгълүмат системасын кулланып, автомат режимда гамәлгә ашырыла.

Регламентның 3.5.2 пунктында күрсәтелгән, шул исәптән пространство мәгълүматларыннан файдалануга бәйле аерым процедураларны үтәү кысаларында пространстволы мәгълүматлар милли системасы эшчәнлеген тәэмин итә торган федераль дәүләт географик мәгълүмат системасыннан файдалану рөхсәт ителә.

Регламентның 3.5 пунктында күрсәтелгән административ процедураларны башкаруның максималь срогы бер эш көнен тәшкил итә.».

1.9. 3.6.5 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:

«3.6.5. Регламентның 3.6.2 – 3.6.4 пунктларында күрсәтелгән процедураларны үтәү техник мөмкинлек булганда, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен билгеләнгән автоматлаштырылган мәгълүмат системасын кулланып, автомат режимда гамәлгә ашырыла.

Регламентның 3.6.2 - 3.6.4 пунктында күрсәтелгән, шул исәптән пространство мәгълүматларыннан файдалануга бәйле аерым процедураларны үтәү кысаларында пространстволы мәгълүматлар милли системасы эшчәнлеген тәэмин итә торган федераль дәүләт географик мәгълүмат системасыннан файдалану рөхсәт ителә.

Регламент пунктында күрсәтелгән административ процедураларны башкаруның максималь срогы 15 эш көне тәшкил итә, алга таба җир кишәрлеген бирү турында хәбәр басылып чыккан очракта - 49 эш көне.».

2. Әлеге боерыкны Интернет челтәрендә Биектау муниципаль районының рәсми сайтында: http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ веб-адрес буенча һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында: http://pravo.tatarstan.ru урнаштырып игълан итәргә.

Рәис вазыйфаларын башкаручы А.Р. Хәсәнов